МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

14.11.2018 г. Казань № 3816-р

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 24.11.2017 ел, № 2718-р карары белән расланган 2018 елга салым базасы кадастр бәясе кебек билгеләнә торган күчемсез милек объектлары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында**

“Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясының 7 пунктына, “Оешмалар милкенә салым турында” 2003 елның 28 ноябрендәге № 49-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 1.1 статьясына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 22.08.2007 № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәнең 3.3.86 пунктына, “Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясының 1 пунктындагы 1 подпунктында күрсәтелгән, үзләренә карата салым базасы кадастр бәясе буларак билгеләнелә торган күчемсез милек объектлары исемлегенә кертелергә һәм электрон рәвештә салым органнарына җибәрелергә тиешле мәгълүматлар составын һәм әлеге исемлекне формалаштыру, алып бару, раслау һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында” 2014 елның 21 ноябрендәге № 896 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясының 1 пунктындагы 1 подпунктында күрсәтелгән, үзләренә карата салым базасы кадастр бәясе буларак билгеләнелә торган күчемсез милек объектлары исемлеген формалаштыру, алып бару, раслау һәм бастырып чыгару тәртибенең 6 пунктына, № 3а-487/2018 административ эше буенча Татарстан Республикасы Югары Судының 2018 ел, 19 июнендәге карарына, № 11-АПГ18-14 административ эше буенча Россия Федерациясе Югары Судының Административ эшләр буенча Суд коллегиясе карарына нигезләнеп:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 24.11.2017 ел, № 2718-р карары белән расланган (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2017 елның 29 ноябрендәге № 2748-р, 2017 елның 27 декабрендәге № 3077-р, 2018 елның 22 июнендәге № 1707-р карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясының 1 пунктындагы 1 подпунктында күрсәтелгән, үзләренә карата салым базасы кадастр бәясе буларак билгеләнелә торган күчемсез милек объектлары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

58 һәм 231 пунктларны төшереп калдырырга.

2. Үзгәрешләр исәпкә алынган Исемлекне электрон формада Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының рәсми сайтында бастырып чыгарырга:

4. Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан соң булган хокук мөнәсәбәтләре өчен үз көчендә була.

5. Әлеге карарның башкарылуын контрольдә тотуны министр урынбасары Р.Р.Мерзакреевка йөкләргә.

**Министр** **А.К.Хамаев**